**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-07, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2026 елның «13» июленнән

№ 153

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының«2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 14 октябрендәге 226 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының«2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 14 октябрендәге 226 номерлы карары белән расланган «2026 - 2030 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлү юлы белән финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә җирле бюджет 2026 елга «758,351» саннарын «827,186» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлү юлы белән финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Республика бюджеты: 2026 ел - 6 883,50 мең сум («Ялкын» ябык футбол манежын җиһазлау);

Программаның «VI. Программа чаралары исемлеге» бүлегенең «II. Республика бюджеты акчалары» өлешенә түбәндәге эчтәлекле 22 нче юл өстәргә:

«

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Спорт белән шөгыльл әнү һәм югары | Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең барлык | «Татарстан Республикас ы Яңа Чишмә муниципаль районының | Яшьләр эшләре, спорт һәм | 2026 - 2030 еллар | - | 6883,50 | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

».

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| нәтиҗәләргә ирешү өчен шартлар тудыру | категорияләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә һәркем файдалана алырлык инфраструктура үстерү | спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Ялкын» ябык футбол манежын җиһазландыру һәм карап тоту | туризм бүлеге | | | | | | | | | | | | |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Бутина Анна Ивановнага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов